КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 31 июль г.Казань № 915

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказын формалаштыруга һәм кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы икътисады ихтыяҗын фаразлау регламентын раслау турында» 2014 ел, 31 март, 208 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказын формалаштыруга һәм кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы икътисады ихтыяҗын фаразлау регламентын раслау турында» 2014 ел, 31 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 21 март, 173 нче; 2017 ел, 16 август, 585 нче; 2017 ел, 1 сентябрь, 626 нчы; 2017 ел, 15 ноябрь, 877 нче; 2019 ел, 22 март, 211 нче; 2022 ел, 14 апрель, 354 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә, «Татарстан Республикасының урта махсус уку йортлары директорлары советы» сүзләрен «Татарстан Республикасы урта һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләр директорлары советы» коммерциягә карамаган партнерлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

$6^1$ пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы

нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирә торган белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнарны кабул итүнең контроль саннарын бүлүгә конкурс үткәрү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 5 ноябрь, 845 нче карары белән расланган Дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирә торган белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнарны кабул итүнең контроль саннарын бүлүгә конкурс үткәрү тәртибенең» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирә торган белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнарны кабул итүнең контроль саннарын бүлүгә конкурс үткәрү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 5 ноябрь, 845 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирә торган белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнарны кабул итүнең контроль саннарын бүлүгә конкурс үткәрү тәртибенең» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказын формалаштыруда һәм кадрлар әзерләүдә Татарстан Республикасы икътисады ихтыяҗларын фаразлау регламентында (алга таба – Регламент):

3 пунктта «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга, «тармак министрлыклары, ведомстволары» сүзләрен «вәкаләтле республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта:

бишенче абзацта «тармак министрлыклары, ведомстволары» сүзләрен «вәкаләтле республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «Тармак министрлыклары, ведомстволары» сүзләрен «Вәкаләтле республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга, «Бюджет учреждениеләре эшчәнлеге мониторингы мәгълүмат-аналитик система-сының автоматлаштырылган системасы» сүзләрен «БАРС. Мониторинг – Социаль яклау» мәгълүмат-аналитика системасы» сүзләренә алмаштырырга, «Россия Федерациясе Стандартлаштыру һәм метрология буенча дәүләт комитетының гамәлдәге норматив актлары (009 – 2016 ГК Белем бирү буенча белгечлекләрнең

гомумроссия классификаторы)» сүзләрен «Белем бирү буенча белгечлекләрнең гомумроссия классификаторы» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «тармак министрлыгы, ведомствосы» сүзләрен «вәкаләтле республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга, «Бюджет учреждениеләре эшчәнлеге мониторингы мәгълүмат-аналитик системасының автоматлаштырылган системасы» сүзләрен «БАРС. Мониторинг – Социаль яклау» мәгълүмат-аналитика системасы» сүзләренә алмаштырырга, «тармак министрлыклары, ведомстволары» сүзләрен «вәкаләтле республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «Тармак министрлыклары, ведомстволары» сүзләрен «Вәкаләтле республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның алтынчы абзацында «Бюджет учреждениеләре эшчәнлеге мониторингы мәгълүмат-аналитик системасының автоматлаштырылган системасы» сүзләрен «БАРС. Мониторинг – Социаль яклау» мәгълүмат-аналитика системасы» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта «тармак министрлыклары, ведомстволары» сүзләрен «вәкаләтле республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктта «Россия Федерациясе Стандартлаштыру һәм метрология буенча дәүләт комитетының гамәлдәге норматив актлары (009 – 2016 ГК Белем бирү буенча белгечлекләрнең гомумроссия классификаторы)» сүзләрен «Белем бирү буенча белгечлекләрнең гомумроссия классификаторы» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка 1 нче кушымта исемендә «(министрлыкның, ведомствоның тулы исеме)» сүзләрен «(вәкаләтле республика башкарма хакимият органының тулы исеме)» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка 3 нче кушымта исемендә «(министрлыкның, ведомствоның тулы исеме)» сүзләрен «(вәкаләтле республика башкарма хакимият органының тулы исеме)» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин